КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 декабрь г.Казань № 1207

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турында» 2004 ел, 30 декабрь, 584 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турында» 2004 ел, 30 декабрь, 584 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 9 октябрь, 507 нче; 2009 ел, 6 апрель, 201 нче; 2009 ел, 19 июнь, 403 нче; 2011 ел, 21 гыйнвар, 33 нче; 2011 ел, 30 декабрь, 1104 нче; 2012 ел, 26 декабрь, 1151 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 938 нче; 2015 ел, 20 гыйнвар, 23 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 817 нче; 2017 ел, 15 февраль, 85 нче, 2017 ел, 29 декабрь, 1073 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1265 нче, 2019 ел, 9 декабрь, 1122 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктның 3.2.2 пунктчасында «2020 елның 31 декабре» сүзләрен «2021 елның 31 декабре» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта:

4.1.1 пунктчада «2020 елның 31 декабре» сүзләрен «2021 елның 31 декабре» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.2 пунктчада «2020 елның 31 декабре» сүзләрен «2021 елның 31 декабре» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«әлеге Нигезләмәгә $1^1$ нче кушымта нигезендә форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

паспортының оешманың кадрлар хезмәтендә, яшәү урыны буенча таныкланган яисә нотариаль рәвештә таныкланган күчермәсе, Россия Федерациясенең пенсия законнары нигезендә пенсия билгеләнүен раслый торган документның күчермәсе, инвалидлык билгеләгәндә - шулай ук инвалидлык билгеләү фактын раслый торган белешмәнең күчермәсе;

хезмәт кенәгәсенең оешманың кадрлар хезмәтендә, яшәү урыны буенча яисә нотариаль рәвештә таныкланган күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр.»;

5.15 пунктта «2020 елның 31 декабре» сүзләрен «2021 елның 31 декабре» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин